СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«22» ноябрь, 2023 ел Алабуга шәһәре № 293

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджеты турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Федераль һәм республика законнары таләпләре, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджеты турында» карарын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлауларын үткәрергә.

3. Массакүләм мәгълүмат чараларында түбәндәгеләрне бастырып чыгарырга:

- 1 нче кушымта нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджеты турында» карары проектын;

- 2 нче кушымта нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм тәкъдимнәр буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен.

4. Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджеты турында» карар проекты буенча гавами тыңлауларны:

2023 елның 7 декабрендә, 14:00 сәгатьтә Алабуга муниципаль районы Советы бинасының зур залында, Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 30 нчы йорт адресы буенча үткәрергә.

5. Алабуга муниципаль районы Советы Аппаратына, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гавами тыңлауларын үткәрүне, әлеге карар буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшмәкәрлеккә ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими комиссиянең карарлар проектын җәмәгать тыңлауларында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып эшләп бетерергә һәм Алабуга муниципаль районы Советы сессиясенә чыгарырга.

Рәис Р.М. Нуриев

Алабуга муниципаль районы
Советының
"22" ноябрь 2023 ел, № 293
карарына 1 нче кушымта

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты турында»

Алабуга муниципаль районы Уставы, Алабуга муниципаль берәмлегенең бюджет процессы турында Нигезләмә нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1 статья

1. 2024 елга Алабуга муниципаль берәмлеге бюджетының (алга таба – бюджет) түбәндәге төп характеристикаларын расларга:

1) район бюджетының фаразланучы керемнәренең гомуми күләмен 3 095 798,1 мең сум итеп;

2) район бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 3 095 798,1 мең сум итеп;

3) район бюджеты кытлыгын (профицитын) 0,00 мең сум итеп;

2. 2025 һәм 2026 елларга район бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) район бюджетының фаразланучы керемнәренең гомуми күләмен 2025 елга 3 066 191,5 мең сум һәм 2026 елга 3 075 362,1 мең сум итеп;

2) район бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2025 елга 3 066 191,5 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар күләмен 51 461,0 мең сум һәм 2026 елга 3 075 362,1 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар күләмен 103 985,2 мең сум итеп;

3) 2025 һәм 2026 еларга район бюджеты кытлыгын (профицитын) 0,00 мең сум итеп.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 1 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

2 статья

1. 2025 елның 1 гыйнвары торышы буенча түбәндәгеләрне расларга:

Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге 0.00 мең сум күләмендә, шул исәптән Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге, нульле билгеләнешле Россия Федерациясе валютасында Алабуга муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча;

2. 2026 елның 1 гыйнварына торышы буенча түбәндәгеләрне расларга:

Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге 0.00 мең сум күләмендә, шул исәптән Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге, нульле билгеләнешле Россия Федерациясе валютасында Алабуга муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча;

3. 2027 елның 1 гыйнварына торышы буенча түбәндәгеләрне расларга:

Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге 0.00 мең сум күләмендә, шул исәптән Алабуга муниципаль районының муниципаль эчке бурычыныңюгары чиге, нульле билгеләнешле Россия Федерациясе валютасында Алабуга муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча;

3 статья

Район бюджетында 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына район бюджетының фаразланучы керемнәренең күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга

4 статья

2024 елда Алабуга муниципаль районы бюджетына Алабуга муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре табышының 2023 ел нәтиҗәләре буенча салым һәм башка мәҗбүри түләүләр керткәннән соң кала торган өлеше 2024 елның 1 июленә кадәр әлеге табышның 30 проценты күләмендә күчерелә.

5 статья

1. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Район бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Алабуга муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Район бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялары (Алабуга муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре) чыгымнар төрләре төркемнәре, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, чыгымнар төрләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Район бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен: 2024 елга 67 848,2 мең сум, 2025 елга 69 280,9 мең сум һәм 2026 елга 70 690,9 мең сум күләмендә расларга.

5. 2024 елда район бюджетының җыелма бюджет расписаниесе күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү өчен нигез булып әлеге статьяда расланган бюджет ассигнованиеләре составында резервланган, чыгымнарны бюджет классификациясе бүлекчәләре буенча әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә каралган акчаларны бүлү тора:

1) 2024 елга 215 326,4 мең сум күләмендә;
2) 2025 елга 215 326,4 мең сум күләмендә;
3) 2026 елга 215 326,4 мең сум күләмендә.

6 статья

Әлеге район Советы карары белән район бюджеты турында каралган чаралар, товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә - юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга субсидияләр, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бирелә.

7 статья

2024 елда Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 4410 статьясы нигезендә район бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен, әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә расларга

8 статья

Әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен расларга:

1) 2024 елга 102 156,7 мең сум күләмендә;
2) 2025 елга 43 614,7 мең сум күләмендә;
3) 2026 елга 23 533,2 мең сум күләмендә.

9 статья

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә муниципаль учреждениеләрне тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә җирлекләр бюджетыннан тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларны исәпкә алып, әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә бүләргә:

1) 2024 елга 457 421,2 мең сум күләмендә;
2) 2025 елга 470 664,1 мең сум күләмендә;
3) 2026 елга 470 585,8 мең сум күләмендә.

Күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслауга юнәлтергә.

10 статья

Алабуга муниципаль районы юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга:

1) 2024 елга 36 089,1 мең сум күләмендә
2) 2025 елга 36 922,6 мең сум күләмендә;

3) 2026 елга 38 059,9 мең сум күләмендә.

Күрсәтелгән бюджет ассигнованиеләрен 2024 елга, 2025 һәм 2026 елларга Алабуга муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлтергә.

11 статья

1. Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, Алабуга муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләренә яңа функцияләр яки вәкаләтләр бирү белән бәйле карарлар кабул итү очракларыннан тыш, Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2024 елда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

2. Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарына 2024 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

12 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык департаменты территориаль бүлеге, төзелгән килешүләр нигезендә, Алабуга муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

13 статья

Район бюджетының 2024 елның 01 гыйнварына калган средстволары, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2023 елда түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Алабуга муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә, 2024 елда Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлтелә.

14 статья

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләүдән, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, әйләнә-тирәлеккә, шул исәптән су объектларына мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында китерелгән зыянны каплау турында дәгъвалар буенча түләүләрдән, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында китерелгән зыянны ирекле каплаганда түләнә торган түләүләрдән Алабуга муниципаль районы бюджетына кертелгән салым булмаган керемнәр Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты раслаган, Алабуга муниципаль районында табигатьне саклау чаралары планы нигезендә, әйләнә-тирә мохиттә җыелган зыянлы объектларны ачыклау һәм бәяләүгә һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү

эшләрен оештыруга, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү, башка чараларга җибәрелә, дип билгеләргә.

15 статья

Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

Алабуга муниципаль районы
Советының
"22" ноябрь 2023 ел, № 293

карарына 2 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм тәкъдимнәр буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуы тәртибе.

1. Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы бюджеты турында» карары проектына тәкъдимнәр:

1. Тәкъдимнәр кушымта нигезендә, үрнәк итеп бирелгән таблица ярдәмендә язма формада түбәндәге адрес буенча тапшырыла:
Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 24 нче йорт

| № т/б | Фикер алышуга чыгарылган мәсьәләләр | Тәкъдимнәр № | Тәкъдимнәр һәм экспертлар киңәшләре, аларны кертү датасы | Тәкъдим кертелде (хупланды) | Мәсьәләне карау нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Күтәрелгән тәкъдимнең формулировкасы | 1.1. | Тәкъдимне тәкъдим итү тексты | Экспертның фамилиясе, исеме, атасының исеме (оешманың исеме) | |

2. Тәкъдимнәр әлеге карар басылып чыккан көннән 2023 елның 27 ноябренә кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.
3. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә:
Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 24 нче йорт,
шәхсән яисә электрон почта адресы аша («Гавами тыңлаулары» конвертында тамга белән) тапшырыла.
Гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр ике көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.
4. Гражданнарның тәкъдимнәре Алабуга муниципаль районы Советы Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм икътисади үсеш, бюджет,

салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка һәм туризм мәсьәләләре буенча даими комиссиягә карау өчен тапшырыла.